ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 апрель, 2016 ел № 7/20

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны һәм счетларга (кертемнәргә) ия булуны, акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) файдалануны тыю турында» 79-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктны өстәргә:

«12) депутат тарафыннан үзенең керемнәре хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматларны тапшырмау яисә күрәләтә ялган яки тулы булмаган мәгълүматлар тапшыру;»;

2) 17 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 9 пунктны өстәргә:

«9) ел саен, хисап финанс елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча, Керемнәр хакында, мөлкәт һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләр хакында мәгълүматларның дөреслеген контрольдә тоту буенча Шәһәр Советы комиссиясенә үзенең керемнәре, чыгымнары хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары хакында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар тапшырырга бурычлы.»;

3) 18 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктын өстәргә:

«1.1 Шәһәр Советында вазифа биләүче депутатларга (Шәһәр Советы Президиумы әгъзалары, Шәһәр Советының даими комиссия рәисе һәм аның урынбасары) Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу һәм счетларга (кертемнәргә) ия булу, акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) файдалану тыела.»;

4) 19 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) 16. Вазифаларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерүче яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынганлык барлыкка килгәндә, бу турыда Шәһәр Советы карары белән расланган тәртиптә шәһәр Хакименә хәбәр итәргә һәм аның мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмауга юнәлтелгән карарларын үтәргә».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

